ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.06.2022 г. Заинск № 311

**«Татарстан Республикасы Зәймуниципаль районы башлыгы грантларытурында» 2019 елның 24 апрелендәге 226 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерымкарарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 октябрендәге 1030 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгы грантлары турында» 2019 елның 24 апрелендәге 226 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. Әлеге карар белән расланган «Мәгарифтә инновацион проектлар» район башлыгы грантын алуга муниципаль конкурс турында нигезләмәнең беренче бүлеген түбәндәге эчтәлекле 1.8 пункты белән тулыландырырга:
«1.8. Конкурс нәтиҗәләре фәнни басмаларда бастырып чыгарылырга тиеш»;
1.2. «Мәгарифтә инновацион проектлар» район башлыгы грантын алуга муниципаль конкурс турында нигезләмәнең 1 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**Зәй муниципаль районы башлыгы грантын бирү буенча конкурс комиссиясе составы**

| | | |
|---|---|---|
| Камалова Регина Николаевна | – | конкурс комиссиясе рәисе, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| Сәфәргалиев Эрнст Рәис улы | – | конкурс комиссиясе рәисе урынбасары,«ТР ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе»МКУ |

| | | |
|---|---|---|
| | | башлыгы |
| Әюпова Венера Мөхлисулла кызы | – | конкурс комиссиясе секретаре, «ТР ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ неңмәгълүмати һәм укыту-методик тәэмин итү бүлеге өлкән методисты |
| **Конкурс комиссиясе әгъзалары:** | | |
| Шәрәфиева Гүзәл Мәхиян кызы | – | мәгариф идарәсе башлыгының тәрбия эшләре буенча урынбасары |
| Вәлиәхмәтова Миләүшә Камил кызы | – | «ТР ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУнең мәгълүмати һәм укыту-методик тәэмин итү бүлеге башлыгы |
| Ларина Альбина Равил кызы | – | Белем бирү учреждениеләре директорлар Советы рәисе, 7 нче Төзелеш округы буенча Зәй шәһәр Советы депутаты, 4 нче шәһәр мәктәбе директоры |
| Куликова Валентина Петровна | – | «Балалар иҗат йорты» МБУДО директоры |
| Иванова Светлана Николаевна | – | «Күкчәчәк» балалар бакчасы» МБДОУ мөдире |
| Вахитова Ирина Александровна | – | Зәй муниципаль районы мәгариф хезмәткәрләренең профсоюз оешмалары советы рәисе |
| Дмитриева Елена Александровна | – | «ТР ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУнеңмәктәпкәчә тәрбия буенча методисты |
| Җиһаншина Гөлнара Мисхәт кызы | – | «ТР ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУнең план-икътисад бүлеге башлыгы |
| Садриева Зөлфирә Әхмәтвәли кызы | – | «ТР ЗМР Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУнең структур бүлекчә җитәкчесе-баш хисапчы |

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Сәфәргалиев Э.Р.
3-27-42